РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

СОВЕТ ИШТУГАНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ САБИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

422050, Республика Татарстан, Сабинский район, п.ж.д.р. Иштуган, ул. Центральная, 11
тел. (84362) 42-0-37

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

САБА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ИШТУГАН АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

422050, Татарстан Республикасы, Саба районы, Иштуган т.ю.р.б., Үзәк урам, 11 йорт
тел. (84362) 42-0-37

e-mail: Isht.sab@tatar.ru

**КАРАР** **РЕШЕНИЕ**

19.12.2022г. №21

Җирле салымнар буенча түләнеп бетмәгән салымнар, пенялар һәм штрафлар буенча бурычларны түләтүгә өметсез дип тануның өстәмә нигезләре турында

Россия Федерациясе Салым кодексының 59 статьясындагы 3 пункты, Россия Федерациясе Федераль салым хезмәтенең «Түләтүгә өметсез дип танылган пенялар, штрафлар һәм процентлар буенча түләнеп бетмәгән салымнарны һәм бурычларны бетерү тәртибен һәм түләтүгә өметсез дип тану шартларын раслаучы документлар исемлеген раслау турында» 02.04.2019 ел №ММВ-7-8/164@ боерыгының 6 пункты нигезендә, Иштуган авыл җирлеге Советы

**КАРАР ИТТЕ:**

1. Җир салымы һәм физик затлар мөлкәтенә салым буенча түләнеп бетмәгән салымнарны һәм бу салымнарның пенялары буенча бурычларны түләтүгә һәм исәптән төшерүгә өметсезлекне тануның өстәмә нигезләрен (алга таба – бурыч) билгеләргә:

– балалар йортларында һәм балалар өчен приютларда тәрбияләнүче, әти-әниләре Ата-ана хокукыннан мәхрүм калган балигъ булмаган гражданнар;
– физик зат вафат булган көннән яисә аны Россия Федерациясенең Граждан процессуаль законнарында билгеләнгән тәртиптә үлгән дип игълан иткәннән соң, барлык варислар мирас хокукыннан баш тарткан очракта, варислар булмаганда яки мирасны кабул итмәгән очракта, өч еллык срок узу;
– салым түләүченең бөлгенлеккә төшүе(банкротлык) турында эштә кулланыла торган процедураларда табылмавы шарты белән, физик затларның җирле салымнар буенча пенялар буенча бурычлары һәм (яки)өч еллык срогы чыккач аларның күләме 100 сумнан артмый;
– «Бөлгенлеккә төшү (банкротлык) турында» 2002 елның 26 октябрендәге 127-ФЗ номерлы федераль закон нигезендә әлеге Федераль закон нигезендә кредиторлар белән исәп – хисапларны тәмамлау йомгаклары буенча түләнмәгән һәм күрсәтелгән Федераль законның 5 статьясы нигезендә агымдагы түләүләргә караган пенялар буенча бурычлар өлешендә гражданны банкрот дип тану.

2. Салым түләүченең бурычын исәптән төшерү әлеге карар, Россия Федераль салым хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча 10нчы номерлы районара ИФНСы тарафыннан бирелгән салым түләүченең бурычы турында белешмә һәм Россия Федерациясе Федераль салым хезмәтенең «Пенялар, штрафлар һәм процентлар

буенча түләнеп бетмәгән салымнарны һәм бурычларны бетерү тәртибен раслау турында» 02.04.2019 ел №ММВ-7-8/164@ боерыгында күрсәтелгән документлар, Иштуган авыл башкарма комитеты тарафыннан салым органына тапшырылган, түләтүгә өметсез дип табылган, түләнеп бетмәгән салымнар, пенялар, штрафлар һәм процентлар буенча бурычларны түләтүгә өметсез дип тану шартларын раслаучы документлар исемлеге нигезендә салым органы тарафыннан башкарыла,

3. Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Иштуган авыл җирлеге Советының «Җирле салымнар буенча түләнеп бетмәгән салымнарны, пенялар һәм штрафлар буенча бурычларны түләтүгә өметсез дип тануның өстәмә нигезләре турында»гы 27.06.2017 елгы №13 карарын үз көчен югалткан дип танырга.
4. Әлеге карарны "Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында түбәндәге адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru, бастырып чыгарырга.
5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотам.

Иштуган авыл җирлеге башлыгы Д.М.Гайнутдинов